**«Иң яхшы татар теле һәм әдәбияты укытучысы» Бөтенрәсәй бәйгесенең йомгаклау этабы**

Казан шәһәрендә «Иң яхшы татар теле һәм әдәбияты укытучысы» Бөтенрәсәй бәйгесенең йомгаклау этабы башланды. Бәйгенең февраль-март айларында узган зона этабында 53 татар теле һәм әдәбияты укытучысы катнашып, шуларның 21е йомгаклау этабына сайлап алынган. Бу исемлектә Балтач муниципаль районы «Балтач гимназиясе»нең татар теле һәм әдәбияты укытучысы **Әхмәтова Рәйсә Шамил кызы** да бар. Йомгаклау этабының беренче турында укытучылар 21-22нче март көнне Казан шәһәренең «Адымнар» – белем һәм татулыкка юл» күптелле мәктәбе укучылары белән сыйныф сәгатьләре, дәресләр үткәрделәр. Соңгы турга узган 12 укытучы 23-24нче март көннәрендә шул ук мәктәптә мастер-классларын һәм методик остаханәләрен тәкъдим итәчәкләр. Берничә турны уңышлы узган укытучыбыз Рәйсә Шамил кызын ихластан котлыйбыз, алга таба да уңышлар телибез. Бәйгенең җиңүчеләре 25нче март көнне тантаналы чарада игълан ителәчәк.

